


# Хатын –кыз язмышы

Әдәби мохиткә язгы ташкын кебек килеп керде Зифа Кадырова . Һәркемгә таныш хис-тойгыларны үзәкләрне өзәрлек итеп тасвирлап, кыска гына вакыт аралыгында «Сагынырсың — мин булмам», «Язмыш сынавы», «Көтеп узган гомер», «Бәхеткә юл кайдан?», « Синсез килгән язлар» исемле әсәрләр бүләк итте .

Зифа Кадырованың әсәрләрендә хатын-кыз сабырлыгы, сынауларга дучар ителгән яралы язмышлар, шатлыгын да, газабын да үзенә сыендырган мәхәббәт - темалары чагыла.




**Кадырова З. Сагынырсың, мин булмам. – Казань: “Идел-Пресс”, 2011. – 304 б.**

«Нинди куаныч_ Сөмбелнең, дәү әнисе килгән. Кызыкай аның белән эч серләрен сөйләшергә ярата, чөнки әбисе кызыксынып тыңлый белә, житмәсә, беркайчан да ачуланмый. Бүген дә Сөмбелнең сөйләр сүзләре бик күп җыелган иде.

Дәү әни, дәү әни, мин шундый чибәр егет белән таныштым. Аны күрсәң иде: үзе озон буйлы, күк күзле, коңгырт чәчле. Ә елмайса , елмайсамы – башларым әйләнеп китә , әбием!


Әллә урысмы?

Юк , ул татар.Ахун егете.

Әй балам, юкка куанасың, минем белүемчә, Ахуннықылар элек- электән читтән кыз алмаган, читкә
кыз бирмәгән….


…Сөмбел, балам, гыйшык –мыйшык уйнап башыңны әйләндермә, укырга керөсең бар….

…Тик яшь кыз чибәр Ахун егете Балаттан башка берни хакында уйлый алмый иде инде…..»





Кадырова, З. А. Язмыш сынавы. - Казан, 2015.- 336 б.

Менә тормыш дигәне ничек бит ул! Ике яшь йөрәк бер- берсен сөеп кавыша. Югары белемле, чибәр һәм культуралы яшь кенә кыз Әлфия һәм шулай ук сөйкемле итагатьле егетләр солтаны булган – Таһир. Шал кадәр пар килгәннәр.Соң боларга бит инде гөрләтеп яшәргә генә кала. Бхетле һәм бөтен булып , тупылдатып балалар үстерер өчен барча шартлар да бар бит, әмма юк шул юк! Көнкүрешнең үз кануннары, үз әшәкелекләре. Шунда ук, көнләшүчеләр, күпсенүчеләр, арага керүчеләр табыла.




**Кадырова З. Көтеп узган гомер. – Казан: “Идел-Пресс”, 2011. – 368 б.**

«….Сыный язмыш кешеләрне, ирләрне-хатыннарны, хәтта бер гөнаһсыз сабый балаларны.
Язмыш, дибез. Берәүләрне язмыш сыный, берәүләр үзләре язмышны.
Бар идеме соң бу язмышларның башка юлы?
Белмим... Язмышларны Ходай кеше туганчы ук язып куя, диләр.  Шулай булгач, бер ул гына белә бу бәндәләрнең язмышларын…»




**Кадырова З. Бәхеткә юл кайдан?. – Казан: “Идел-Пресс”, 2013. – 256 б**.

"... Ник бу бәхет дигәнең шулчаклы авыр урау юллар белән килә икән? Аны көтеп алырга күпме сабырлык кирәк. Күкләрдә күпләрнең йөрәк өзгеч ялварулары, күз яшьләре ак болыт булып йөзәдер. БӘХЕТКӘ ЮЛ КАЙДАН? ЮЛ КАЙДА-А-АН? Җиһанны ярып, күк күкри, яшен яшьни, "Бәхет үз кулыгызда, аяк астыгызда!" дип җиһан җавап бирәдер. Тик кешеләр аңламыйлар, һаман "бәхеткә юл кайдан, юл кайдан?" дип кычкыра бирәләр ..."




**Кадырова З. Синсез килгэн язлар.Р оман. – Казан: “Идел-Пресс”, 2015. – 192 б.**

«….Курэсенме,дустым,бу бит безнен алга Ходай куйган сынаулар,шул ук вакытта бер-беребезгэ тотынып торырга сина-мине,мина-сине хэм йорэк янганын басарга шушы жилле кар-буранны жибэргэн.Борчылма,дустым,без югалмабыз. Курэсенме,лампочка янмаса да,кар яктысы бар, карангы булса да,юл куренэ...энэ кар оемнэре,без аны ерып утэбез.Капка алдын кар оеме сырган... булса сон...аны да корибез дэ жылы ойгэ кереп чумабыз.Тормышта да шулай,кеше язмышы алдында тумгэклэр,кеше абына-сортенэ,оем-оем кар бураннарын ера-ера алга атлый....тик егылырга гына ярамый,иртэгэ тора алмавын бар.Э иртэгэ буран басылыр да бар донья тынып калыр.Без дэ хэзер арып кайтабыз да ятып йоклыйбыз...яна кон кем белэ ни китерэсен,бэлки,шатлык безнен урамга да кереп чыгар..."

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!